СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 08 » декабрь 2020ел № 10

**Урта Курса авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 декабрендәге 78 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Урта Курса авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (06.04.2019 ел,№83, 08.11.2019 ел, №102, 20.02.2020 ел, №107, 14.08.2020 ел, № 116 үзгәрешләр белән)**

2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Курса авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 декабрендәге 78 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Урта Курса авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (06.04.2019 ел,№83, 08.11.2019 ел, №102, 20.02.2020 ел, №107, 14.08.2020 ел, № 116 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары тиешле вазыйфа биләгән вакытта, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатыннан, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый."

2) 30 статьяның 30.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу

турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина